**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 55**

## I. Тестларны эшләгез. (10 балл)

1. Рәт гармониясенә буйсынган сүзләр рәтен тап. (**1 балл**)

а) җиһан, укучы, көнбатыш

**ә) агачлар, атлар, ятимнәр**

б) төньяк, суык, тимераяк

в) миңа, мисал, китап

2. Әдәби әйтелешне бозып сөйләүнең сәбәбен билгелә. (**1 балл**)

а) гел чит телдә сөйләшү

ә) басымны дөрес куймау

б) сүзләрне дөрес язмау

в) **әдәби әйтелеш белән дөрес язылыш арасында аерма булу**

3. Кайсы сөйләштә **[з]** тартыгын сакаулаштырып әйтәләр? **(1 балл)**

а) көнчыгыш диалектта

**ә) минзәлә сөйләшендә**

б) урта диалектта

в) көнбатыш диалектта

4. Морфологик принцип ул – (**1 балл**)

а) сүзләрнең элекке язылышын саклап язу

ә) ишетелгәнчә язу

б) рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләрне рус телендәгечә язу

в) **сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язу**

5. Кайсы диалектта сүзләрне **Җ** -ләштереп әйтәләр? (**1 балл**)

а) көнчыгыш диалектта

ә) минзәлә сөйләшендә

**б) урта диалектта**

в) көнбатыш диалектта

6. Кайсы рәттәге сүзләрдә **һ** хәрефе языла? (**1 балл**)

а) пө...тә, ...ат, рә...әт, ...алык

ә) шә...әр, ...әлак, ...ыял, ә...әмият

**б) һава, зинһар, даһи, һәйкәл**

в) ...өнәр ,...әтер, тари..., ил...ам

7. Гомумтөрки сүзләр булган рәтне билгеләгез. (**1 балл**)

**а) сары, биш, күз**

ә) имтихан, рөхсәт, дәфтәр

б) кәгазь, армия, почта

в) дару, рәсем, җиһан

.

8. Сыйфат сүз төркеме нәрсәләр белән төрләнә? (**1 балл**)

а) зат-сан

ә) заман

б) барлык-юклык

**в) дәрәҗә**

9. *Сизгер* сүзенең синонимын табыгыз. (**1 балл**)

а) елгыр

**ә) уяу**

б) җитез

в) сихри

10. *Барыйм, барыйк* фигыльләре кайсы фигыль төркемчәсенә карый? **(1 балл)**

а) хикәя фигыль

**ә) теләк фигыль**

б) боерык фигыль

в) шарт фигыль

**II. Теоретик бирем (14 балл)**

**Сыйфат фигыль турында языгыз һәм мисаллар белән аңлатыгыз.**

Сыйфат фигыль – сыйфат һәм фигыль билгеләрен берләштергән затланышсыз фигыль төркемчәсе. Аның өч заман формасы була.

1) Хәзерге заман сыйфат фигыль (-учы/-үче; -а/-ә, ый/-и + торган ярдәмче фигыле): фамилиясен алыштыручы (кеше), авырмый торган (егет). -учы/-үче формалы сыйфат фигыль сыйфатланмышы төшеп калганда исемләшә һәм килеш, сан, тартым белән төрләнә: фамилиясен алыштыручылар бар, шушы фамилияне йөртүчене эзләделәр. Кайбер сыйфат фигыльләр исемгә күчкәннәр: сатучы, очучы, язучы, укытучы;

2) Үткән заман сыйфат фигыль (-ган/-гән, -кан/-кән): сөенечтән типкән (йөрәк), шатланган (Самат). Үткән заман сыйфат фигыль сыйфатланмышы төшеп калганда исемләшә һәм килеш, сан, тартым белән төрләнә: шатланганын күрделәр, кайтканда безгә кер;

3) киләчәк заман сыйфат фигыль (-ачак/-әчәк, -ячак/- ячәк; -ар/-әр, -ыр/-ер, -р; -асы/-әсе, -ыйсы/-исе). Киләчәк заман сыйфат фигыльнең -асы/-әсе, ыйсы/-исе формасы исемләшә: әйтәсе (сүз), әйтәселәр әйтелде. Бу сыйфат фигыльнең юклык төре булмый.

**III. Гамәли-иҗади бирем (31 балл)**

Карчык тавыкларга җим ясап тора иде, хат ташучы килеп керде. Хатны кулына алды да аптырап калды. Катлы-катлы кәгазь ябыштырылган хатка карап торды да агарып китте. Оныгының дәфтәр битенә язган хатын күргәч, йөрәген ниндидер хәвеф-хәтәр ярып узды. «ДӘҮ ӘНИ! Яратам, кил, кил, кил, кил! Айзадә».

– И Айзадә, ниләр булды икән сиңа, балакаем? – дип, өйгә кереп китте.

– Ни булды, карчык, – диде Галихан.

– Айзадәгә нидер булган! Әйтәм аны хатлары, хәбәрләре юк...

Карт та «кил, кил» дип язылганга озак карап торды. Аның маңгае, җыерчыклы йөзе тагын да каралып китте. Озак кына сүзсез торгангач:

– Карчык, җыен, Казанга китәбез – дип, өйгә кереп китте.

Р. Шәйдуллина-Мураттан

1. *Хәвеф-хәтәр* сүзенең мәгънәсен аңлатыгыз. (**3 балл**)

**Хәвеф-хәтәр** – курку хисе, куркыныч янау. Хәвефләнү, борчылу, шикләнү.

2. Тексттан сыйфат фигыльләр булган җөмләләрне күчереп языгыз, сыйфат фигыльләрнең заманнарын билгеләгез. **(4 балл)**

1) Катлы-катлы кәгазь **ябыштырылган** хатка карап торды да агарып китте. Ябыштырылган (хат) – үткән заман сыйфат фигыль.

2) Карт та «кил, кил» дип **язылганга** озак карап торды.

Язылганга – язылган (хатка), исемләшкән үткән заман сыйфат фигыль, юнәлеш килешендә.

3. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(4 балл:** *һәр җавапка 0,5 балл***)**

Кил – кит, файдалы – зарарлы, пышылдап – кычкырып, саран – юмарт, тәрбияле – тупас, тиз – озак, сай – тирән, шикәр – тоз.

4. Текстны укы. Татар теленә башка телләрдән кергән сүзләрне (алынма сүзләрне) язып ал. (**5 балл:** *һәр сүзгә 0,5 балл*)

Картлар өйгә керделәр. Галихан бабай, ишек янындагы сумкасын күтәреп, Зифа әби белән кухняга юнәлде. – Менә, Асия, аз гына авыл

күчтәнәче бар иде, авыз итәрсең, – дип, карт бер литрлы банка белән балны, каклаган каз, каймак, варенье, китап битенә төргән йомыркаларны өстәлгә куйды.

Р. Шәйдуллина-Мураттан

**Алынма сүзләр:** Галихан, сумкасын, Зифа, кухняга, Асия, литрлы, банка, варенье, китап, өстәлгә.

5. “Заманча аралашу чаралары” дигән темага 14-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(15 балл)**